ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 416-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А. Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 416-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 20 апреле
№ 1944-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 бүлегенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш); Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2023 елның 4 апреле), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^6$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^6$ статья. Депутатлар тарафыннан кайсы да булса затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аларга мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе

1. Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

2. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) хәбәрнамә тапшырган депутатның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

б) хәбәрнамә тапшырган депутатныңяшәү урыны, телефоны;

в) депутатка коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, урыны, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат;

г) депутатны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

д) депутат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозулар билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылу яисә гамәл кылмау) җентекләп тасвирлау;

е) депутатны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарткан зат (затлар) турында билгеле булган барлык белешмәләр;

ж) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

з) хәбәрнамә тапшырган депутатның имзасы.

3. Хәбәрнамәгә кайсы да булса затларның депутатны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү хәлләрен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $9^2$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$9^2$ статья. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан кайсы да булса затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аларга мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) кайсы да булса затларның аны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итүнең барлык фактлары турында тиешле мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә прокуратура органнарына яисә Татарстан Республикасы Рәисе администрациясенә хәбәр итәргә тиеш.

2. Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә.

3. Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

2) хәбәрнамә тапшырган зат били торган дәүләт вазыйфасының тулы исеме, яшәү урыны, телефоны;

3) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, урыны, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат;

4) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар);

5) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозулар билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылу яисә гамәл кылмау) җентекләп тсвирлау;

6) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарткан зат (затлар) турында билгеле булган барлык белешмәләр;

7) хәбәрнамәгә имза кую датасы;

8) хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның имзасы.

4. Хәбәрнамәгә кайсы да булса затларның Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан мөрәҗәгать итү хәлләрен раслый торган барлык булган материаллар өстәп тапшырыла.».

**3 статья**

Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын аңлатма**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 5 һәм $12^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 591-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

«Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның $4^{1-1}$ өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар кайсы да булса затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итүнең барлык фактлары турында тиешле мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә прокуратура органнарына яисә башка дәүләт хакимияте органнарына хәбәр итәргә тиеш. Шулай ук «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 19 статьясындагы 16 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә хәбәр итү бурычы Дәүләт Советы депутатларына да йөкләнә.

Закон проектында Дәүләт Советы депутатларының һәм дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның аларны нинди дә булса затлар тарафыннан коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү тәртибе раслана.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларыннан тыш) кайсы да булса затларның аны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итүнең барлык фактлары турында тиешле мөрәҗәгать булган көннән алып биш көн эчендә прокуратура органнарына яисә Татарстан Республикасы Рәисе администрациясенә хәбәр итәргә тиеш.

Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) ирекле формада язмача әзерләнә. Хәбәрнамәдә хәбәрнамә тапшырган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта); ул били торган дәүләт вазыйфасының тулы исеме, яшәү урыны, телефоны; аңа коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү датасы, урыны, вакыты һәм рәвеше турында мәгълүмат; аны

коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, вәгъдә бирү, алдалау, көч куллану һәм башка алымнар); ул җәлеп ителгән коррупциячел хокук бозулар билгеләре булган гамәлләрне (гамәл кылу яисә гамәл кылмау) җентекләп тасвирлау; аны коррупциячел хокук бозулар кылуга тарткан зат (затлар) турында билгеле булган барлык белешмәләр; хәбәрнамәгә имза кую датасы; хәбәрнамә тапшырган затның имзасы булырга тиеш.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.